**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 10 февраль № 77

г. Казань

2017 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында

«2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2016 ел, 28 ноябрь, ТРЗ-93 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә үсемлекчелек өлкәсендә, орлык бәрәңге һәм ачык грунт яшелчәләрен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә затлы орлыкчылыкны үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә җитен сүсе җитештерүне үстерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә күпьеллык үсентеләр үстерүдә булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сөтле терлекчелектә продуктивлыкны арттыруга юнәлдерелгән, Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сарык һәм кәҗәләрнең ана башларын саклау һәм үрчетү чыгымнарының бер өлешен каплауга

Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә агросәнәгать комплексы объектларын төзү һәм модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен, шулай ук техника һәм җиһазлар сатып алу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә культуртехника, урман агромелиорациясе һәм гидромелиорация чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда агросәнәгать комплексында инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда агросәнәгать комплексында кыска вакытлы кредитлар (заемнар) буенча процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда озак вакытлы, уртача вакытлы һәм кыска вакытлы кредитлар буенча процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы иминиятләве шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләү өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда эшләрен башлап җибәрүче фермерларга дәүләт ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган грантлар бирү тәртибен;

2017 елда гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган грантлар бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган грантлар бирү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2016 ел, 28 ноябрь, ТРЗ-93 нче Татарстан Республикасы Законында күздә тотылган ассигнованиеләр исәбеннән 2017 елда конкурс нигезендә бирелә торган түбәндәге грантларның гамәлгә куючысы булырга:

эшләрен башлап җибәрүче фермерларга – 140,0 млн.сум күләмендә;

крестьян (фермер) хуҗалыкларына – 155,0 млн.сум күләмендә;

матди-техник базаларын үстерү өчен авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына – 150,0 млн. сум күләмендә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\77.docx